**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Трой-Урай авыл җирлеге составына керүче Гремячка авыл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

23 ноябрь , 2021 ел № 2

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге 18 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлеге Башлыгының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең Трой-Урай авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2022 елның 8 ноябрендәге 1 номерлы карары нигезендә, 2022 елның 23 нояберендә узган гражданнар җыенының 5 нче номерлы йомгаклау беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең Гремячка авылы торак пункты гражданнар җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең Гремячка авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан һәм 90 яшьтән өлкән гражданнардан гайре, 600 сум күләмендә үзара салым кертергә. Тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

-Трой- Урай авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

-Трой- Урай, Гремячка авылларында су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау һәм Троицкий-Урай авылында су башнясы, скважина мәйданчыгынын коймасын ремонтлау (шартнамә буенча материаллар сатып алу, эшләр өчен түләү)- Авыл җирлеге торак пунктларында энергия саклаучы

яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр сатып алу, түләү)

- Авыл җирлегенең торак пунктларында территорияләрне төзекләндерү.
- Су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү (Техник паспортлар, су башняларына техник планнар ,Троицкий Урай һәм Гремячка авыллары скважиналарын эшләү)
- Трой-Урай авылындагы скважина бинасын ремонтлау
- Трой-Урай авылында чүп-чарның контейнер мәйданчыкларын ремонтлау

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Трой-Урай авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Трой-Урай авылы, Мәктәп урамы, 13 нче йорт,Кама – буе урамы,9 йорт;Гремячка авылы, Александров урамы 24 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының
Трой-Урай авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Сафин